ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.05.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 42

с. Русское Макулово

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар хисабына тормышка ашырыла торган чыгымнар юнәлешен раслау турында**

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында Югары Ослан муниципаль районы Советының 2010 елның 24 апрелендә кабул ителгән 45-499 номерлы «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 пункты нигезендә һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 пункты нигезендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар чыгымнар юнәлешен расларга,
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Макыл авыл җирлеге Башлыгы** **Л.Р. Цветкова**